## Задания заключительного тура Акмуллинской олимпиады по татарскому языку и литературе для учащихся 10-11 классов, студентов СПО

1. Буш урыннарга исемнәрнең данә исәбен белдергән сүзләрне куегыз (5 б):

1 капчык ... салы

икмәк ... бөртеге

1 уч ... туфрак

салам ... өеме

10 баш ... сугар

1 кочак ... салам

1 тотам ...

арыш ... көлтәсе

2 кап ...

чәчәк ... гөлләре

2. Саннар артына яшеренгән мәкальне табып языгыз (10 б).

1, 12 38, 13, 23, 34, 21, 23, 13, 1, 16, 6, 1 12, 18, 14, 6, 34, 10 13, 25, 7, 36, 15, 11.

Ат ятторганда талдың күрешми.

3. Канатлы сүзләрне рус теленә тәрҗемә итегез: (12 б)

Ахиллес үкчәсе ахиллесова пята,

Шөкатьсез үрдәк баласы гадкий утёнок,

Дары мичкәсендә дары бар әле есть еще порох в пороховницах,

Очкыннан ялкын кабына из искры возгорится пламя,

Крокодил күз яше крокодиловы слёзы,

Аю хезмәте күрсәтү медвежья услуга.

4. Түбәндәге формулаларга туры килгән сандхи очракларына 1-әр мисал китерегез (3+3=6):

е + ә = ә ________________________________

ы+у=у ____________________________________

5. Дөрес җавапны билгеләгез (4 б.):

*Бергә алар язгы урман һавасы суладылар, яр буенда саргылт тал ПИПИЛӘРЕ өзделәр* (Н.Фәттах). Җөмләдә аерып бирелгән сүз:

- профессионализм
- архаизм
- диалектизм
- неологизм

Алар билгеле бер формага буйсынган булалар. Аларда мәҗбүри җөмлә калыплары, сүзтезмәләр, тәгъбирләр кулланыла, алардан зур төгәллек сорала.

- матур әдәбият әсәрләре
- рәсми эш кәгазьләре
- публицистик әсәрләр
- драма әсәрләре

Бирелгән кереш сүзләр нинди мәгънә белдерәләр?

*ихтимал, күрәсең, бәлки, ахрысы, ахры*

– билгесезлекне
– үтенүне
– сөйләүченең төрле тойгысын
– фикер эзлеклелеген

Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәренең тулы текстын беренче булып кульязмада әзерләгән әдип:

– С.Сараи
– Г.Утыз Имәни
– Й.Баласагунлы
– Колшәриф

6. Дөрес җавапларны билгеләгез: (3 б)

1. Әсәрләрнең жанрын языгыз:

“Сөннәтче бабай” хикәя

“Беренче театр” драма

“Сак-Сок” бәет

7. Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» драмасында автор югары күтәргән сыйфатлар (1 сыйфат – 1 б. =5 б.).

яшәүгә омтылыш
шаш халыклык
әхлаклык
тормыш тәҗрибәсе
тапкыр акыллылык

8. М. Акмулла “Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт берлән” дип язган. Автор турында 5 факт яз (10 б.)

1) бик яшьли ятим кала; 2) казак далаларында муллалык кыла; 3) татар, башкорт, казах шагыйре; 4) мәгърифәт тематикасына еш мөрәҗәгать итә; 5) кешеләрне белемле булырга өнди

9. Җәяләрне ачып, дөрес языгыз (5 б).

(1)Сулар ага... (2) Җир (йөзендә) йөзендә сулар бер (туктаусыз) бертуктаусыз агалар (да) агалар. (3)Җәй агалар, яз агалар, көз агалар... (4)Агым сулар кешеләрнең чир (чорларын) чир-чорларын кайгыларын, языкларын алалар (да) алалар да еракларга, упкыннарга, чоңгылларга ыргыталар. (5)Агым сулар, җир (өстенең) җир өстенең чүп (чарларын) чүп-чарларын юып алып, үзләрендә юк итәләр. (6)Шулай ел (да) ел да җир яңара, җир яшәрә.

(7)Җир яңара, җир яшәрә... (8)Өзелмичә, туктамыйча, бөек Чулман кебек, Әтил кебек, көн (төн)_көн – төн_ җирдә тормыш ага.

(9)Яз килде, яз!... 10)Киң Чулманга – кояш белән, ай (йолдызлар)_ай – йолдызлар_ белән яшьтәш Чулманга ашыгып төрле (яктан) сулар ага...(Н. Фәттах).

10. Бирелгән өзек нинди әсәрдән? (2 б.) _Итил суы ака торур_

11. Түбәндәге тел күренешләре булган җөмлә номерларын куярга (5 б):
1) ялгызлык исемнәре
2) парлы сүзләр
3) гөнаһ сүзенә синоним
4) юклык формасындагы фигыль
5) вакыт мәгънәсен белдергән исем

| 1) | 2) | 3) | 4) | 5) |
|---|---|---|---|---|
| 8, 10 | 4, 5, 8 | 4 | 8 | 3, 6, 8, 9 |

12. 5нче җөмләдә хәбәрнең төре (3 б.)_фигыль хәбәр_

13. Өзекне дәвам итеп эссе языгыз. Күләме 200 сүздән ким булмаска тиеш (30 б.)

Сулар ага... Су бит ул җир куенының
җиденче катламнарын ашап бәреп чыга. Саф
су безнең бәяләп бетмәслек байлыгыбыз.
Чишмәләр челтерәп агып чыгып ага елга-
ларга, диңгезләргә илтеп куя. Бер тукталу-
сыз агып торган елгалар, чишмәләрнең
бурычы бит.
Җир йөзендә күпме сулар бер тукталусыз
агалар да агалар. Борын борыннан бирле
ата бабаларыбыз чишмә, суларны кадер
тотканнар, кибәргә ирек бирмәгәннәр,
чиста су яшәү чыганагы. Язын ташып,
җәен тыныч гына, көзен моңсу булып ага-
лар да агалар. Бормаланып аккан сулар
кешеләрнең чир чорларын, кайгыларын,
язуларын алалар да, еракларга, упкын-
нарга, чоңгылларга агызалар. Җырларда
җырлаганча: никадәр авыр булса да,
агым суларга кара диләр... Ягып нак-
кан чишмә суларының кайчы агымна-
ры авыруларны сихәтләндерергә, хезмәт
кешесенә көч, куәт бирер. Җир анабыз бир-

гән иң зур байлыгыбызның берсе — эчәр суыбыз. Аккан сулар булган җирдә яшеллек тә, сайрар кошлар да аерым бер ямь бит ул. Дулкын дулкын булып аккан сулар кешеләрне авыр уйлардан арындыра. Агым сулар җир өстенең чүп-чарларын юып, юк итәләр.

Һәр аккан суның үз тавышы, үз моңы, үз холкы бар. Бер инеш сулар исә әкрен генә, тын гына ага, икенчеләре шаулап — шаулап, юлында булган каршылыкларны җиңеп шаулап ага.

Менә шулай ел артып ел үтә, җир яңара, җир яшәрә. Еллар үткән саен җир куенныннан ургылып яңа сулар агып чыга. Агып чыгалар да, шаян дулкыннары, артан искән йомшак җил малайлары белән уйнап-уйнап туктаусыз көн-төн, агалар да агалар... Ә язын исә, бөтен табигать уянганда елгаларда шаулап бозлар китә, табигать чистара.

Суда көч, хәрәкәт, сусыз дөньяда яшәеш юк. Суларның да көче, җаны, рухы бар. Сулар акмаса, җир йөзендә хәрәкәт, туктаукта бәрәкәт, күңелләрдә — наз булмас иде.